**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**
**Печищинского сельского поселения**
**Верхнеуслонского муниципального района**

422592, с.Печищи, ул. Декабристов, д. 35 а
тел. (84379) 2-29-44 факс: (84379) 2-29-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге СОВЕТЫ**

422592, Печище авылы, Декабристлар ур., 35 нче йорт
тел. (84379) 2-29-44 факс: (84379) 2-29-44

# РЕШЕНИЕ

2015 елның 1 апреле № 49-246

Печищи авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Печищи авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Печищи авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 мартындагы 48-240 номерлы карары нигезендә, Печищи авыл җирлеге башлыгының «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2015 елның 3 мартындагы 48-240 номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Печищи авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2015 елның 24 маена җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2015 елда авыл җирлегенең җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр кешесеннән 450 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларны юлларга риза булырсызмы:

- Печищи авыл җирлеге территориясендә урнашкан, гомуми суммасы 298350 сум булган үзәк сууткәргеч торба челтәрен ремонтлау һәм реконструкцияләү.

ӘЙЕ ЮК".

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка чыгарырга һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе урынбасары,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге  башлыгы урынбасары О.В.Боева